OMEGA OFFICIAL TIMEKEEPER
КӨН СӘГАТЬ МИНУТ СЕКУНД
2015 ЕЛГЫ СУ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА 16 НЧЫ ФИНА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНА КАДӘР
FINA FÉDÉRATION INTERNATIONALE DE NATATION

# БӘҺРӘЙННӘН КИЛГӘН 10 ЯШЬЛЕК ЙӨЗҮЧЕ КЫЗ: “КАЗАН АКВАПАРКЫН КҮРӘСЕМ ҺӘМ БУ ХАКТА СЫЙНЫФТАШЛАРЫМА СӨЙЛИСЕМ КИЛӘ”

03.08.2015, 12:20

СПОРТ

Күрсәткечләре нинди булуга карамастан, Алазин Тарек Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты елъязмасына кереп калачак. Үзе яраткан йөзү төрендә ул әлеге Чемпионатның рекордын стартка кадәр куя алды. Эш шунда, Бәһрәйн милли командасының вәкиле төп халыкара акватика турнирының иң яшь катнашучысы булып тора. Кечкенә Алазинга хәзер 10 яшь. Әмма кыз үзен яклый да, аңгәмәдәшен үз яшенә хас булмаган төпле җаваплары белән шаккатыра да ала. Оештыру комитетының матбугат хезмәте спорт күзәтүчесе моның шулай икәненә инанды.

- Алазин, сез ДЧ-2015нең иң яшь катнашучысы икәнегезне беләсезме?

- Әйе, һәм моны тою бик рәхәт.

- Бу яшегездә Дөнья чемпионатына ничек сайлана алдыгыз соң?

- Барысы да җиңел аңлатыла: мин Бәһрәйн җыелма командасының иң тиз йөзүчесе (көлә).

- ???

- Квалификациядә сайлап алуда мин барлык көндәшләремнән дә тизрәк булып чыктым. Олы кызлар бар идеме дисезме? Әйе, әлбәттә. Әмма анда эләгү өчен миңа башта дистанциядәге бөтен яшьтәшләремне узарга туры килде.

- ДЧ-2015тә үз алдыгызга нинди максат куясыз?

- Хәзер минем өчен иң мөһиме –ярыш тәҗрибәсен иң югары дәрәҗәдә туплау. Шулай ук танылган Олимпия чемпионнарының техникасын күзәтү һәм, бәлки, аларның арсеналыннан үземә файдалы булган берничә алымны да үзләштерү.

- Әллә Казанга җиңү хыялы белән килмәдегез инде?

- Күз күрер (елмая). Әмма моның өчен иң әбәт вакытны күрсәтергә кирәк булачак.

- Кайсы дисциплиналарда катнашырга уйлыйсыз?

- Мин 50 метрда ирекле стиль һәм баттерфляй белән чыгыш ясаячакмын.

- Сезнең карашка, бу дисциплинада көндәшләрегез кем булырга мөмкин?

– Беркемне дә аерып әйтмәс идем, ник дигәндә, көндәшләр барысы да көчлеләр. Үзегез дә аңлыйсыздыр, Дөнья чемпионатында көчлеләр генә катнаша. Кем җиңәрме? Дистанцияне башкалардан тизрәк йөзеп узучы җиңәчәк (елмая).

– Зур турнирларда катнашу тәҗрибәгез булмавы финалга бару юлында киртә булмас микән?

– Булмаска тиеш. Мин бит кичә генә йөзә башлаган кеше түгел, халыкара масштабтагыларда булмаса да, элегрәк тә турнирларда катнашканым булды. Мин беркемнән дә курыкмыйм!

– Ватаныгызда өйрәнүләр ничек уза?

– Бәһрәйндә без йөзү белән атнага 5 тапкыр: иртән һәм кичен шөгыльләнәбез.

– Шундый тыгыз графикны белем алу белән берләштерә аласызмы?

– Моның әлегә миңа уңайсызлык тудырганы юк. Уку да, йөзү дә канәгатьлек бирә. Мәктәптә иң яраткан фәнем - математика.

– Сезнең ДЧ-2015кә баруыгызга сыйныфташларыгызның мөнәсәбәте нинди булды?

– Алар әле минем Казанга сәяхәтем турында белмиләрдер дә. Киткәнче мин аларга бу турыда әйтергә өлгермәдем. Илемә кайткач, монда күргәннәремне аларга сөйләрмен, билгеле. Кемдер мине телевизордан да күрергә мөмкин әле.

– Алайса, аларга сөйләр өчен шәһәр турында күбрәк хатирәләр тупларга кирәк икән...

– Расписаниемә шәһәр буенча сәяхәтне керттем. Җирле Аквапаркка бик барасым килә. Аны автобус тәрәзәсеннән күреп калдым.

– Алазин, җавапларыгызга караганда, Сез бик батыр кыз. Әти-әниләрегез кемнәр?

– Әнием – укытучы, әтием – элек профессиональ йөзүче булган. Безнең йөздә гаилә династиясе дисәң дә була, кече сеңлем шулай ук йөзү белән шөгыльләнә.

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА